| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2016 Казан ш. № 7-13/т

Яр Чаллы шәһәре «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан керә торган тимер юлларда күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

«Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Керә торган тимер юлларда Яр Чаллы шәһәре «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифларны әлеге карар кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Керә торган тимер юлларда Яр Чаллы шәһәре «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында 2013 елның 8 февралендәге 7-2/т санлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
26.08.2016 № 7-13/т
карарына кушымта

Керә торган тимер юлларда Яр Чаллы шәһәре «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

I бүлек. Максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| № п/п | Күрсәтелүче хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Максималь дәрәҗәдә чик тариф сумнарда (НДСтан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1. | Лесоцех участогы буенча 4 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 80,08 |
| 2. | Закамье участогы буенча 3 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 79,83 |
| 3. | Цементный участогы буенча 4 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 77,08 |
| 4. | Авторемонтный участогы буенча 3 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 77,08 |
| 5. | Нефтебаза участогы буенча 7 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 111,78 |
| 6. | Индустриальный участогы буенча 19 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 142,61 |
| 7. | БСИ участогы буенча 17 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 139,95 |
| 8. | ЗЯБ участогы буенча 24 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 138,06 |
| 9. | ТЭЦ участогы буенча 26 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 200,42 |
| 10. | Заводской участогы буенча йөк ташу, шул исәптән | | |
| 10.1 | 19 км ераклыкка вагоннарның йөк күтәрүенең түбән коэффициентын кулланучы* йөкләр | 1 вагон | 2 376,33 |
| 10.2 | 19 км ераклыкка вагоннарның йөк күтәрүенең норматив коэффициентын кулланучы* йөкләр | 1 тонна | 83,05 |

* - 1997 елның 10 февралендәге РФ Икътисад Министрлыгы бәяләр Департаменты белән килешенгән тарифлар формалаштыруга һәм җыемнарның сәнәгый тимер юл

транспорты белән башкарылучы йөк ташуга, йөкләү һәм йөк бушату эшләре һәм башка хезмәтләргә Методик тәкъдимнәр нигезендә йөк күтәрүнең коэффициенты оешма тарафыннан фактик мәгълүматлар нигезендә билгеләнә.

## II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнагый тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарылган, әмма «Тарифлар» дип аталган 1 бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләргә тарифлар Россия Федерациясе транспорт Министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р санлы боерыгы белән расланган сәнагый тимер юл транспорты тарафыннан башкарылган эшләргә һәм башка хезмәт күрсәтүләргә тарифларны һәм җыемнарны формалаштыру буенча Методик тәкъдимнәргә нигезләнеп, яклар килешүе белән билгеләнә.

2. Вагоннарның йөк күтәрүчәнлегеннән норматив файдаланып, йөк ташу һәм төяү-бушату эшләре өчен түләү, йөкнең факттагы авырлыгыннан чыгып, заказчыдан түләтелә.

3. Йөк ташуга түләү алу өчен ераклык, тулы санга кадәр түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге